**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7983**
**08.12.2021**

Башкарма комитетның 2021 елның 15 июнендәге 4016 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкның аерым категорияләре өчен түләүсез физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Яр Чаллы шәһәре, Габдулла Тукай исемендәге яр буе һәм В. Гостев урамы кисешкән район адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:52:000000:4009 булган җир участогында спорт-сәламәтләндерү комплексы төзү һәм киләчәктә аны эксплуатацияләү буенча муниципаль-шәхси партнерлык турында 2018 елның 26 апрелендәге килешүне тормышка ашыру максатында, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкның аерым категорияләре өчен түләүсез физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү тәртибен раслау турында» 2021 елның 15 июнендәге 4016 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкның аерым категорияләре өчен түләүсез физкультура-сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 1 һәм 2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) аз керемле һәм күп балалы гаиләләрдәге балалар;

2) сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле затлар һәм картлык буенча пенсионерлар;»;

2) 3 пунктның 1, 2, 6, 7 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле затлар һәм картлык буенча пенсионерлар өчен бассейнда тренер белән сәламәтләндерү дәресе;

2) сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле затлар һәм картлык буенча пенсионерлар өчен тренер белән дәвалау физик культурасы дәресе;

6) тренер белән йога буенча төркемле дәрес;

7) тренер белән аква-аэробика төркемле сәламәтләндерү дәресе.»;

3) 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлектәге 6 һәм 7 пунктчалар өстәргә:

«6) күп балалы гаилә таныклыгының күчермәсе;

7) пенсия таныклыгы яки картлык буенча пенсия билгеләү турында белешмә күчермәсе.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитетының Үзәк районы хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Башкарма комитетының Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетының Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов